


Гаилә - бәхет ачкычы. Ә кеше жиһанга бәхет очен туа. Бәхет фәкать гаилә аша гына килә. Тату гаилә – бәхетле гаилә, ди олкәннәр. Хак сvзләр. Бары бер-беренне хормәтләv, бер-береннен кадерен белv генә гаиләне тату һәм ботен итә. Ә татулык, әлбәттә, бәхеткә юл яра. Ләмберә авылында шушы гади генә кагыйдәләрне тормыш девизы итеп бергә матур гомер кичерә Эльвина белән Рушан Казаковлар. Алар яшәvнен мәгънәсен, тормышнын кадерен белеп, тирә-юньдәгеләргә vрнәк булып яши.   Бар нәрсәләре дә житеш, тормышлары тvгәрәк аларнын. Гомумән, тормышта куелган максатларга ирешv очен ныклы ихтыяр коче, тырышлык, vжәтлек кирәк. Ә Рушан белән Эльвинанын икесенә дә хас бу сыйфатлар.
Эльвина Наиль кызы белән Рушан Раис улы Казаковлар әлеге гvзәл пар биш бала тәрбияләп vстерәләр: Артем, Александр, Самир (икесе мәктәп укучылары, кечесе балалар бакчасына йори) уллары һәм ике искиткеч игезәк кызлары бар!
Эльвина vзенен китапханәче һонәрен ярата, кvнел кушуы буенча сайлаган, әмма анын очен, гаилә учагын саклаучы буларак, барыннан да бигрәк нәкъ менә гаилә, балалар кадерле. Ул vзе тумышы белән Кадошкино районынын Большие Поляны авылыннан. Бvген М.Е.Евсевьев исемен йорткән педагогик университеты (Эльвина тәмамлаганда институт иде) биология-химия факультетын тәмамлый. Әмма язмыш vз уенын уйный: мәктәп урынына китапханәгә эшкә килә. Тормыш юллары һәм бергә гаилә булып яшәvләре дә кызыклы аларнын. Эльвина Рушан белән Саранскида узган футбол буенча Донья чемпионатында танышканнар. Эльвина чемпионатнын стюарды була, ягъни кунакларны стадионга керv урынында каршы ала, трибуналарга ничек vтәргә икәнен әйтә, башка конкvреш мәсьәләләрендә дә ярдәм итә. Ә шул ук вакытта хокук саклау органнарында эшләгән Рушан, башка полицейскийлар белән бергә, тәртипне кvзәтеп торган. Шул мәлдә танышканнар да.
- Беркайчан да футбол белән аеруча мавыкмадым, ә нәкъ менә ул минем алдагы язмышымны билгеләде дә куйды, - дип колә Эльвина. Ике ел дәвамында мәхәббәт очрашулары дәвам итә. Аннары Большие Полянада, Эльвинанын әтисе Рәшит Фәрит улы белән әнисе Альфия Зәкәрья кызы Кильдеевлар оендә, борынгы гореф-гадәтләр буенча (никях кәләшнен туган жирендә узарга тиеш) никях укыталар. Шуннан алып гаилә булып Саранскитан Ләмберәгә кvчеп бvгенге конгә кадәр яшиләр.
Рушан башта Саранскида конвой хезмәтендә эшләгән, аннары Россия Эчке эшләр министрлыгынын ММО «Лямбирский» га - дежур частька кvчкән, аннан льготалы пенсиягә чыккан. Әмма эшләвен дәвам итә: офицер формасын гражданнар формасына алыштырып ПАО «ТЕТНЕФТЬ»тә эшли.
Гаилә - тормыш нигезе. Yз оендә бәхетле булганнар гына бәхетле, ди бездә халык. Казаковларнын гаиләләре чын-чынлап шундыйлардан. Аларнын олкән уллары Артемга унике яшь. Доньяда барыннан да бигрәк Артем рәсем ясарга ярата. Шуна кvрә аны әти-әнисе балалар сәнгать мәктәбенә биргәннәр. Ә менә икенче улы Александр музыкага тартылуны мирас итеп алган булса кирәк.

- Минем гениалогик агач буенча, барыбыз да иҗади кешеләр - музыкаль яктан сәләтле, - ди Эльвина. - Якын туганым булган Идрис абзыем, vзлегеннән ойрәнсә дә, талантлы баянчы иде. Зәкәрья абзыем - рәссам. Бәлки, Артем аларга ошыйдыр? Әбием Саранын тавышы матур, кочле иде - татар халык җырларын башкарганда кvнел тvрләрен тибрәтә иде! Авылыбызда хормәтле башлангыч сыйныф укытучысы булып хезмәт иткән Рима апамнын да вокаль сәләте гаҗәеп кочле; гомере буе «Дуслык» ансамблендә җырлый. Алина сенелемнен дә тавышы искиткеч ямьле. Сvз унаеннан, Эльвина vзе дә мәктәптә дә, институтта да vзешчән сәнгать коллективында актив катнашкан. Бигрәк тә ана татар халык җырлары якын.

Казаковларнын оченче улы Самирга килгәндә, ул әле бик кечкенә, ниндидер мавыгулар турында сойләргә иртә: нибары дvрт яшь кенә. Игезәк сенелләре Аделия белән Амелиягә сигезенче ай - аларнын барысы да алда. Балаларнын барысы да, әти-әниләре, туганнары vрнәгендә, талантлы шәхес булып vсәрләр дип ышанырга урын бар. Нәкъ менә шундый тырыш гаиләләрдә vткән буыннарнын ин яхшы традицияләре саклана да инде.

**Наилә НАСЫРОВА**